ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 435-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 435-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 13 июле
№ 2062-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында**

**1 статья**

Татарстан Республикасы Җир кодексына кушымтаның 2 пунктына (2005 елның 18 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 8 (II өлеш); 2005, № 1(I өлеш), № 12 (I өлеш); 2006, № 7 (I өлеш); 2007, № 1 (I өлеш), № 4; 2008, № 5(I өлеш); 2009, № 7-8 (III өлеш); 2010, № 11; 2011, № 11 (I өлеш); 2012, № 3, № 5 (I өлеш); 2013, № 1; 2014, № 3, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2016, № 40 (I өлеш); 2017, № 41 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 60 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 20 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 3 (I өлеш), № 17 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) индустриаль (сәнәгать) паркын булдыру, һәм (яки) үстерү, һәм (яки) модернизацияләү, һәм (яки) реконструкцияләү буенча инвестиция проекты Татарстан Республикасы шәһәр округы территориясендә инвестицияләрнең гомуми күләме 350 миллион сумнан, Татарстан Республикасы муниципаль районы территориясендә – 15 миллион сумнан ким булмавын күздә тота. Шул ук вакытта инвестицияләрнең гомуми күләме индустриаль (сәнәгать) паркының потенциаль резидентлары тарафыннан башкарыла торган инвестицияләрне исәпкә алып билгеләнә;»;

2) 3 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында»**
**Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

Россия Федерациясе Җир кодексы һәм Татарстан Республикасы Җир кодексы нигезләмәләре, күрсәтелгән объектлар, инвестиция проектларының Россия Федерациясе субъектлары законнары белән билгеләнгән критерийларга туры килү шартларында, социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш объектларын урнаштыру, масштаблы инвестиция проектларын гамәлгә ашыру өчен дәүләт милкендә яки муниципаль милектә торучы җир кишәрлеген юридик затларга торгилар үткәрмичә бирүне күздә тота.

Закон проекты Татарстан Республикасы Җир кодексында билгеләнгән критерийларга төзәтмәләр кертүне күздә тота.

Индустриаль (сәнәгать) паркының идарәче компаниясенең инвестицияле проектын гамәлгә ашырганда эш урыннары булдыру критериен, аны гамәлгә ашыруны мониторинглау һәм аның үтәлешен контрольдә тоту мөмкин булмау сәбәпле, бетерергә тәкъдим ителә.

Индустриаль (сәнәгать) паркының инвестицион проектына инвестицияләрнең гомуми күләме буенча 350 миллион сумнан ким булмаган критерийны шәһәр округлары һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнары өчен дифференциацияләргә тәкъдим ителә.

Бүгенге көндә республиканың барлык сәнәгать паркларында 1500дән артык резидент эшли, 52,2 мең эш урыны булдырылган, 2021 ел йомгаклары буенча резидентларның кереме 404,7 млрд. сумнан артык тәшкил иткән (2022 елның 9 ае йомгаклары буенча – 263,3 млрд. сум). Бу шулай ук Казанда «Химград» технополисы, Чаллыда «Мастер» Кама индустриаль паркы кебек эре инфраструктура объектлары, шулай ук республиканың һәр муниципаль районында диярлек булдырылган сәнәгать парклары. Аларның сәнәгать үсеше өчен гомуми мәйданы 2,2 мең гектардан артык.

Инвесторлар өчен инвестицияләр күләме бертөрле булганда, Казан, Чаллы кебек инфраструктурасы үсеш алган зур шәһәрләрдәге сәнәгать парклары кызыклырак, билгеле.

Муниципаль районнар территорияләрендә сәнәгать паркларын үстерүне стимуллаштыру максатыннан закон проекты белән алар өчен кирәкле инвестицияләр күләмен 15 миллион сумга кадәр киметү тәкъдим ителә.

Закон проекты дустанә булмаган дәүләтләр тарафыннан моңарчы күрелмәгән санкцияләр басымы шартларында Татарстан Республикасы муниципаль районнарында кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү өчен инфраструктура объектларын булдыруга һәм үстерүгә акча кертергә планлаштыручы инвесторларга өстәмә ярдәм чараларын кертүгә юнәлдерелгән.

**«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында»**
**Татарстан Республикасы закон проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.